ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.11.2019 Казан шәһәре № 184

«Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының 2018 елның 31 июленнән 82 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабреннән 883 номерлы карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кертелгән үзгәрешләр белән бәйле б о е р ы к б и р ә м:

«Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының 2018 елның 31 июленнән 82 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәреш кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Рәис С. Е. Иванов

Татарстан Республикасының
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
2018 елның 31 июленнән 82
номерлы карары тарафыннан
расланган
(Татарстан Республикасының
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
2019 елның 19 ноябреннән
184 номерлы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына, шулай ук Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнеп чыгарыла торган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар проектларына (алга таба – актлар, актлар проектлары) ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү һәм ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу процедурасын билгели.

1.2. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июленнән 172-ФЗ номерлы федераль кануны, Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февраленнән 96 номерлы карары тарафыннан расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 29 июненнән УП-575 номерлы указы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 12 декабреннән 883 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза

тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июненнән УП-575 номерлы указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августыннан 580 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

1.3. Ришвәтчелеккә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм акт проектларында ришвәтчелек факторларын ачыклау һәм аларны киләчәктә юкка чыгару.

1.4. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза үз көчен югалткан яисә гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

1.5. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза, шул исәптән бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган ришвәтчелек факторлары акт әзерләү өчен җаваплы Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе тарафыннан юкка чыгарыла.

## 2. Актларга һәм актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү

2.1. Актларга һәм актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш бүлеге башлыгы яисә аның вазыйфаларын башкаручы башка хезмәткәр (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан үткәрелә. Күрсәтелгән вазыйфаи зат шулай ук Дәүләт комитетында Ришвәтчелеккә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) алып бару өчен җаваплы (әлеге Тәртипкә 1-нче кушымта).

2.2. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү өчен актлар һәм актлар проектлары инициативасы буенча әлеге актны кабул иткән (акт проектын эшләп чыгару өчен җаваплы) Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи затка җибәрелә.

2.3. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза Журналда акт (акт проекты) теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә үткәрелә.

2.4. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2-нче кушымтасында бирелгән форма буенча бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тәкъдим ителгән акт реквизитлары (актның исеме);

актта (акт проектында) ришвәтчелек факторлары булу яисә булмау;

актның (акт проектының) ришвәтчелек факторлары булган конкрет нигезләмәләре (булган очракта);

ришвәтчелекне юкка чыгару өчен акт (акт проекты) нигезләмәләрен үзгәртү йә аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр (ришвәтчелек факторлары ачыкланган очракта).

2.5. Актка (акт проектына) ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат тарафыннан әзерләнгән һәм имзаланган бәяләмә төзелгән көнне әлеге актны (акт проектын) җибәргән Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенә тапшырыла.

2.6. Актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе (эшләп чыгаручы) ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган ришвәтчелек факторлары күрсәтелгән бәяләмәне алгач, аның җитәкчесе белән яраштыру буенча өч көн эчендә аларны норматив хокукый акт проектын эшләп бетерүдә исәпкә ала һәм эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка кабат карауга җибәрә.

Экспертизага җибәрелгән актта (акт проектында) ришвәтчелек факторлары юк икән, актны (акт проектын) эшләп чыгару өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе кызыксынган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән актны (акт проектын) Дәүләт комитеты рәисенә имзага җибәрә яисә актны (акт проектын) кызыксынган органнарга һәм оешмаларга яраштыру өчен җибәрүне тәэмин итә.

## 3. Актларга һәм акт проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Дәүләт комитетының рәсми басылып чыккан норматив хокукый актлары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында: http://tourism.tatarstan.ru/ (алга таба – сайт) яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизаны һәм алар буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын үткәрү максатларында урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-порталы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизаны һәм алар буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын үткәрү максатларында урнаштыру өчен Мәгълүмати ресурста (http://tatarstan.ru/regulation) (алга таба – бердәм региональ интернет-порталы) урнаштырылган Дәүләт комитеты тарафыннан эшләп чыгарылган норматив хокукый актлар проектлары ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр яки конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

3.2. Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнә торган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан канун чыгару инициативасы тәртибендә Рәсәй Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль кануннар проектларына, Татарстан Республикасы кануннары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Дәүләт комитеты аларны үзенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм бердәм региональ интернет-порталында аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга яраштыруга җибәргән эш көне дәвамында урнаштыра.

3.3. Дәүләт комитеты актлары проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен акт проектын әзерләү өчен җаваплы Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе акт проектын вазыйфаи затка карау өчен җибәрелгән эш көне дәвамында акт проектын сайтта һәм бердәм региональ интернет-порталында эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп урнаштыра.

3.4. Сайтта урнаштырылган акт проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы мондый урнашу көненнән алып биш эш көненнән дә ким түгел.

3.5. Дәүләт комитетына срок чикләрендә килгән актка (акт проектына) ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә (алга таба – бәяләмә) кергән көннән соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм идарә тармаклары арасындагы системасында теркәлә һәм актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенә җибәрелә.

3.6. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим итү характерына ия. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә, әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Дәүләт комитеты тарафыннан аны теркәгән көннән 15 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яисә физик затка мотивацияле җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган ришвәтчелек факторлары турында мәгълүмат яисә ачыкланган ришвәтчелек факторларын төшереп калдыру ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш), анда ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яки) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый акт проектында ачыкланган ришвәтчелек факторы белән килешмәү сәбәпләре чагылдырыла.

3.7. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча киләсе бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертлар сыйфатында Рәсәй Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән бәяләмәләр;

Рәсәй Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килмәгән бәяләмәләр.

Әлеге Тәртипнең 3.7 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта Дәүләт комитеты мондый бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлгән көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтара.

3.8. Акт проектына ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган ришвәтчелек факторлары акт проектын эшләп бетерү вакытында юкка чыгарыла.

Проектны эшләп чыгаручы тарафыннан акт проектына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәргәннән соң үзгәрешләр кертелгән очракта, акт проектына кабат ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрелергә тиеш.

3.9. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Дәүләт комитетының акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне кушып, вазыйфаи затка кабат карауга акт проектын тапшыра. Кабат карау өч көн эчендә башкарыла.

3.10. Әгәр ришвәтчелек факторлары актта ачыкланган булса, Дәүләт комитетының әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмәне теркәгән көннән алып өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү яисә аның үз көчен югалтуын тану турында чаралар күрә.

3.11. Эшләп чыгаручы аның тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан канун чыгару инициативасы тәртибендә Рәсәй Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль кануннар проектларында, Татарстан Республикасы кануннары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында ришвәтчелек факторлары булуы турында дәлилләгән ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, эшләп чыгаручы күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ришвәтчелеккә каршы экспертиза бәяләмәсен, шул исәптән бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең килешмәвен нигезләгән аңлатма язмасын кушып кертә.

## 4. Норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы

4.1. Дәүләт комитеты эшләп чыгарыла торган норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итә.

4.2. Җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында норматив хокукый актлар проектлары аларга ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизаны һәм алар буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын үткәрү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-порталы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасының Рәсми порталында урнаштырыла (http://tatarstan.ru/regulation) (алга таба – Мәгълүмати ресурс).

4.3. Мәгълүмати ресурста җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү өчен гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары урнаштырыла.

4.4. Җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында киләселәр урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актлар проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) үз көчләрен югалткан дип тану турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән эшләп чыгару срогы җәмәгатьчелек фикер алышуының минималь срогыннан кимрәк булган норматив хокукый актлар проектлары (Мәгълүмати ресурста урнашкан көннән биш эш көненнән дә кимрәк);

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яисә чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актлар проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар проектлары;

террорчылыкка каршы көрәш чараларын тормышка ашырганда, шул исәптән террорчылыкны финанслаганда дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен регламентлаучы норматив хокукый актлар проектлары;

бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында норматив хокукый актлар проектлары;

мөлкәт белән эш иткәндә билгеләнә торган бәяләрне (түләү күләмнәрен) билгеләү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын канунннардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектлары;

суд карарларын, прокурор илтифат итү актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт функцияләрен башкару административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасының норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актлар проектлары.

4.5. Җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда инициативасы буенча проектны эшләп чыгарган структур бүлекчә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуы башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

4.6. Эшләп чыгаручы тарафыннан билгеләнә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы срогы Мәгълүмати ресурста урнашкан көннән алып биш эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

4.7. Инициативасы буенча проектны эшләп чыгарган структур бүлекчә тарафыннан норматив хокукый акт проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы нәтиҗәләре буенча эшләп бетерү турында карар кабул ителгән очракта, эшләнеп

беткән норматив хокукый акт проекты шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында урнаштырыла.

4.8. Мәгълүмати ресурста норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы, җәмәгатьчелек фикер алышуы срогы тәмамланганнан соң, 30 көн эчендә актның (акт проектының) җаваплы эшләп чыгаручысы ришвәтчәлеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү барышында ачыкланган ришвәтчелек факторлары турында, җәмәгатьчелек фикер алышуы барышында килгән тәкъдимнәр турында әлеге Тәртипнең 3-нче кушымтасында күрсәтелгән форма нигезендә аларны карау нәтиҗәләрен чагылдыручы җыелма мәгълүмат урнаштыра.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 1-нче кушымта

# Ришвәтчелеккә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары хисап журналы

| Актның (акт проектының) экспертизага килү датасы | Актны (акт проектын) тәкъдим иткән структур бүлекчә | Актның (акт проектының) исеме | Ришвәтчелек нормаларының булуы/булмавы | Бәяләмәне төзү датасы | Искәрмәләр (кабат экспертиза үткәрү турында мәгълүмат, кабат экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү датасы) (актлар проектларына карата) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 2-нче кушымта

Ришвәтчелеккә каршы экспертиза бәяләмәсе

____________________________________________________________________________
(норматив хокукый акт реквизитлары яки норматив хокукый акт проектның

____________________________________________________________________________
исеме)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________
(килү датасы)

____________________________________________________________________________
(экспертиза үткәрү датасы)

«Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабреннән 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары
(ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү нигезе)

Актта (акт проектында) ришвәтчелек нормаларының булуы яисә булмавы;
____________________________________________________________________________

Актның (акт проектының) ришвәтчелек нормаларын үз эченә алган конкрет нигезләмәләре:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Ришвәтчелекне бетерү өчен формулировкаларны үзгәртү яисә аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Вазыйфаи зат _____________________ _____________________________
(Имза) (Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 3-нче кушымта

Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) проект буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы нәтиҗәләре буенча җыелма мәгълүмат

______________________________________________

(норматив хокукый акт төре, норматив хокукый акт проектының исеме)

______________________________________________

Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза

| п/п № | Эксперт (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)/аккредитация турында боерык реквизитлары | Ачыкланган ришвәтчелек факторы | Эшләп чыгаручының аңлатмалары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Җәмәгатьчелек фикер алышуы

| п/п № | Фикер алышуда катнашучы (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)/электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Эшләп чыгаручының аңлатмалары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Килгән тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |